КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 14 июль г.Казань № б-1322

Халык арасында авиацияне популярлаштыру, яшьләрнең авиация өлкәсендә белемнәрен күтәрү, Россиянең һава очышы һәм авиатөзелеш өлкәсендә казанышларын күрсәтү максатларында, шулай ук Россия авиациясе оешуының 110 еллыгы, ТАССР төзелүнең 100 еллыгы һәм Казан вертолет заводына нигез салуның 80 еллыгы уңаеннан:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Казан вертолет заводы» гавами акционерлык җәмгыяте, С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы, югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, «Россиянең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле җәмгыятенә (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасының Үзәк аэроклубы» коммерциягә карамаган автоном оешмасы һәм «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыятенең (алга таба – оештыручылар) 2020 елның 25 июлендә «Казан» гаилә үзәге янындагы территориядә «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен (алга таба – авиация бәйрәме) оештыру һәм үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу боерыкка теркәлгән кушымтада күрсәтелгән составта «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетын төзергә.

3. Авиация бәйрәмен оештыручыларга:

яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу шартларында профилактика чараларын саклап, чара үткәрүне тәэмин итәргә, шул исәптән:

чара мәйданчыгына керү урынында катнашучыларның һәм тамашачыларның тән температурасын үлчәүне,

оештыручыларның һәм тамашачыларның сулыш органнарын шәхси саклау чараларын (битлек, респираторлар) куллануны,

катнашучыларның һәм тамашачыларның кулларын тире антисептиклары белән эшкәртү мөмкинлеген,

гомуми кулланылыштагы урыннарны дезинфекцияләүне,

файдаланылган битлекләрне куркынычсыз җыюны;

социаль дистанцияне исәпкә алып, чара үткәрү мәйданчыгын 4 кв.метрга 1 кеше исәбеннән тулылындыруны күздә тотарга.

Авиация бәйрәме мәйданчыгында эшчәнлекнең башка төрләре (җәмәгать туклануы, сәүдә, күңел ачу чаралары һ.б.), яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу куркынычы шартларында мондый мондый эшчәнлек төрләрен башкару өчен эшләнгән санитария-эпидемиология таләпләрен һәм рекомендацияләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан республика территориясендә мондый эшчәнлекне торгызу турында карар кабул ителгән очракта гына гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводына – «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалына, «Казан вертолет заводы» гавами акционерлык җәмгыятенә, «МВЕН» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, «Россия ДОСААФының Татарстан Республикасы үзәк аэроклубы» коммерциягә карамаган автоном оешмасына, «Авиасервис» ачык акционерлык җәмгыятенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә авиация бәйрәмен үткәргән вакытта очыш күрсәтү программасын оештыруны;

«Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыятенә авиация бәйрәмен оештыручыларга авиация бәйрәменең очыш программасында катнашучы һава судноларын кабул итүдә һәм алрга хезмәт күрсәтүдә булышлык күрсәтүне;

«Һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт корпорациясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татаэронавигация» филиалына, Федераль һава транспорты агентлыгының Идел буе төбәкара территориаль һава транспорты идарәсе белән берлектә, оештыручыларга авиация бәйрәменең очыш программасын әзерләүдә һәм демонстрацияләүдә булышлык күрсәтүне.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына оештыручыларга авиация бәйрәмен әзерләүдә һәм үткәрүдә булышлык күрсәтергә, шулай ук Татарстан Республикасының авиация тармагы оешмаларына һәм предприятиеләренә аларда булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе белән берлектә, түбәндәгеләрне оештырырга:

Татарстан Республикасының муниципаль районнарыннан һәм шәһәр округларыннан педагогларның һәм балаларның авиация бәйрәмендә булуын;

авиация бәйрәмендә авиамодель ясаучыларның күрсәтмә чыгышларын һәм күргәзмәләрен.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Һәлакәтләр медицинасы республика үзәге бригадаларын җәлеп итеп, авиация бәйрәмендә катнашучыларга шартнамә нигезендә медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре тарафыннан бүлеп бирелә торган, планлаштырылган маршрутлар нигезендә балалар йөртүне гамәлгә ашыра

торган транспорт чараларын «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат тәэмин итү системасы аша мониторинглауны һәм күзәтеп торуны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырырга.

10. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

оештыручыларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күрсәтмә очышлар башкаруга рөхсәт алуда булышлык күрсәтүне;

оештыручыларга «Казан» гаилә үзәге янындагы территориядә чаралар оештыруда булышлык күрсәтүне;

2020 елның 25 августында «Казан» гаилә үзәге янындагы территориядә автомобиль транспорты өчен Сибгат Хәким урамы буенча автомобиль юлын ябуны оештыруны;

Кремль яр буе һәм «Казан» гаилә үзәге яр сызыкларында йөзүне тыю турында мәгълүмат аншлаглары урнаштыруны;

елга акваториясендәге вакыйгаларга карата оператив чара күрү өчен «Казан» гаилә үзәге янындагы Сибгат Хәким урамы ягыннан Казансу елгасы култыгында вакытлыча муниципаль коткару посты оештыруны.

11. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе һәм «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының 35 нче янгынга каршы федераль хезмәте махсус идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең 1 нче махсус янгыннан коткару часте белән берлектә, оештыручыларга авиация бәйрәмен үткәрү вакытында янгын куркынычсызлыгы иминлеген Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин итүдә булышлык күрсәтергә.

12. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына оештыручыларга авиация бәйрәмен үткәрү урыннарында гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне һәм юл хәрәкәте иминлеген оештыруны тәкъдим итәргә.

13. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына авиация бәйрәмен мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

14. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 14 июль, б-1322 нче
боерыгына кушымта

«Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен
әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе |
| Зарипов Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Саматов Тимур Илгиз улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абраковнов Алексей Павлович | А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университетының – КАИның реклама-күргәзмә эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Абросимова Мария Юрьевна | «ЭНИКС» акционерлык җәмгыятенең маркетинг һәм реклама бүлеге белгече (килешү буенча) |
| Авдонина Любовь Геннадьевна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәте идарәсе җитәкчесенең Татарстан Республикасы буенча урынбасары (Татарстан) (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Әсәдуллина Алсу Мөниб кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Билалов Ренат Харис улы | «Дәүләт кулланма оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе акционерлык җәмгыятенең документлар белән идарә итү һәм контроль идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бульхин Артур Кашап улы | Федераль һава транспорты агентлыгының Идел буе төбәкара һава транспорты территориаль идарәсенә караган очышлар куркынычсызлыгы буенча инспекция бүлегенең төп белгече-эксперты (килешү буенча) |
| Венедиктов Юрий Владимирович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган су объектларында кешеләр иминлеге бүлеге башлыгы – Татарстан Республикасының азсыешлы суднолар буенча баш дәүләт инспекторы (килешү буенча) |
| Виниченко Владислав Валентинович | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Волошин Дмитрий Анатольевич | «Авиапром» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – очу хезмәте идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гаффаров Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Гималтдинов Фирдүс Салих улы | «Татарстан» дәүләт телевизион һәм радиотапшырулар компаниясе «Бөтенроссия дәүләт телевизион һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры (килешү буенча) |
| Гурьянов Артем Александрович | «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең персонал бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Динниулов Дамир Равил улы | «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Зәйнетдинов Ринат Рәфгать улы | «Россиянең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле җәмгыятенә (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасының Үзәк аэроклубы» коммерциягә карамаган автоном оешмасы башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зуев Андрей Борисович | «Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» акционерлык җәмгыяте генераль директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Ибәтуллин Әскәр Айрат улы | Россия федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Идрисов Ранис Әнвәр улы | өстәмә белем бирүче «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Карманников Алексей Владимирович | «Казан авиация технологияләре фәнни-тикшеренү институты» акционерлык җәмгыятенең һәм «Казан агрегат заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең маркетинг хезмәте башлыгы (килешү буенча) |
| Карпович Дарья Геннадьевна | «КАПО-Композит» акционерлык җәмгыятенең эшләр идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Коршунов Валерий Викторович | «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыятенең аэродром белән тәэмин итү буенча директоры (килешү буенча) |
| Левин Александр Юрьевич | «Авиасалон» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Лотфуллин Раил Фәрид улы | «М.П.Симонов исемендәге Тәҗрибә-конструкторлык бюросы» фәнни-җитештерү берләшмәсе акционерлык җәмгыятенең маркетинг бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мигачева Светлана Михайловна | «Казан электр техникасы заводы» гавами акционерлык җәмгыятенең маркетинг бүлеге башлыгы – коммерция директорының маркетинг һәм тышкы икътисадый эшчәнлек буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Мингалиев Илдар Равил улы | «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе (килешү буенча) |
| Миргалимов Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |

| | |
|---|---|
| Михайлов Лев Александрович | «Һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт корпорациясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татаэронавигация» филиалы директорының һава хәрәкәтен оештыру буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полициясе башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча) |
| Осенкова Дарья Игоревна | «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыятенең документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Ризванова Алинә Анатольевна | «МВЕН» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының коммерция мәсьәләләре һәм маркетинг буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Сабирова Гөлнара Ильяс кызы | «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Садыйков Айрат Тәфкил улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсенең күзәтчелек һәм профилактика чараларын оештыру бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлимуллин Илдус Әмир улы | «Электроприбор» ачык акционерлык җәмгыятенең кадрлар бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Семенов Лев Леонидович | «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Соркина Жанетта Ваисовна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының балаларга өстәмә белем бирү бүлеге башлыгы |
| Сторчевой Олег Георгиевич | Һава транспорты федераль агентлыгы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Суин Олег Юрьевич | «Казан авиапредприятиесе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының очыш эшләрен оештыру буенча урынбасары – очыш хезмәте директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хәбибрахманов Дамир Әмир улы | «Радиоприбор» акционерлык җәмгыятенең персонал буенча директоры (килешү буенча) |
| Хәбибуллина Зилә Шәмсемөхәммәт кызы | «Тулпар Аэро Групп» идарә итүче компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тышкы коммуникацияләр буенча директоры (килешү буенча) |
| Хәйруллин Данис Мансур улы | «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең персонал буенча директоры (килешү буенча) |
| Цыкун Георгий Александрович | «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводының штурман хезмәте буенча очу-сынау станциясе башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Шаһимәрданов Гадел Дамир улы | «Казан вертолет заводы» гавами акционерлык җәмгыяте аппараты җитәкчесе – идарәче директор урынбасары (килешү буенча) |
| Шапаев Иван Иванович | «Казан Гипронииавиапром» акционерлык җәмгыятенең техник директор урынбасары – баш инженеры (килешү буенча) |
| Яһүдина Елена Константиновна | «Элекон заводы» акционерлык җәмгыятенең персоналны үстерү бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча). |